**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 30 » 07 2021 № 243

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ комиссия төзү турында» 01.02.2021 ел, №45 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ комиссия төзү турында» 01.02.2021 ел, №45 карары белән расланган «Аксубай муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламенты» 2 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1 һәм 2.3 пунктларда «җитәкче» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. 2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ комиссия рәисе рәис урынбасары һәм административ комиссиянең җаваплы секретаре арасында вазыйфаларны бүлә, аларның функцияләрен Татарстан Республикасы Законы белән бирелгән вәкаләтләр чикләрендә билгели.».

1.3. 2.8 пунктны төшереп калдырырга.

1.4. 2.13 пунктының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Статистик хисаплылыкны дөрес һәм үз вакытында тапшырган өчен җаваплылык Административ комиссия рәисенә, ә аның урынбасарына йөкләнә.».

1.5. 3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ хокук бозулар турындагы эшләр административ комиссия утырышларында карала. Административ комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында карар аның Рәисе тарафыннан, ә булмаганда-рәис урынбасары тарафыннан, административ хокук бозулар турында беркетмәләр һәм башка материаллар кергән очракта, әмма айга 2 тапкырдан да ким түгел, кабул ителә.».

1.6. 3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ комиссия утырышында катнашу мөмкин булмаган очракта, рәис, рәис урынбасары һәм комиссия әгъзалары бу хакта административ комиссия утырышына кадәр бер эш көне эчендә административ комиссиянең җаваплы секретаренә хәбәр итәргә тиешләр.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aksubayevo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты эшләр идарәчесе М.М. Дәүләтшинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты финанс һәм мөлкәт
белән идарә итү буенча житәкчесенең
беренче урынбасары И.И. Муратшин